**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы № 109 2018 елның «03» сентябреннән

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 12 статьясы нигезендә,

Уразай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. **Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:**

Сез 2019 елда Уразай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) ял итүне оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру; (бәйрәм чараларын оештыру һәм уздыру);

2) Уразай авыл җирлеге урамнарында яктыртуны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм аларны алыштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

3) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

4) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру.

"ӘЙЕ" "Юк".

2 Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында:

Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Уразай авылы, Энгельс ур., 65 йорт.

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис: А.М. Шәрифуллина